**Тәхау, К.Н.**

Кондызлар илендә

***Балалар өчен әкият***

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2010

Күксу инеше мәһабәт имән астыннан агып чыккан көмеш сулы чишмәдән башлана. Чишмә башта, бормалана-бормалана, урман эченә кереп югала. Аннан, үз юлында тагын өч чишмәне очратып, шаулап аккан инешкә әверелә, ә инеш исә, үз чиратында, зур елгага барып тоташа.

Бу җирләр, кеше аягы басмагангамы, аеруча җанлы һәм матур. Инешнең ян-якларында зур-зур усаклар, таллар үсеп утыра. Кояш чыккач, дөнья нурга күмелә, су өсте көмеш төсле ялтырый башлый. Тирә-як чут-чут итеп сайраган кошлар тавышыннан тынып тормый.

Менә шундый гүзәл Күксу инеше буенда инде бик күп еллар кондызлар гомер итә.

# КОНДЫЗБАЙ ЙОРТ САЛА

Кондызбай карт һәм аның карчыгы Кондызбикә Күксу инешенең елгага кушыла торган урыныннан ярты чакрым чамасы ераклыктагы җирдә яшиләр. Алар бирегә моннан берничә ел элек күченеп килгәннәр иде. Тирә-ягында мәһабәт агачлар, куаклар үсеп утырган су буен бик яраттылар алар.

Кондызбай, торган җиреннән канәгать булса да, бу җәйне яңа йорт салырга уйлады.

– Кулда көч барында, үзең теләгәнчә яшәп калырга кирәк, – диде ул.

Ярдәмгә улларын чакырды. Яшь кондызлар, әтиләренең теләген ишетүгә үк, эшкә дә керештеләр. Башта су астыннан яр эченә авыш тишек казыдылар, аннары, су өсте тигезлегеннән өскәрәк күтәрелеп, өй буласы урынны хәстәрләргә керештеләр.

Кондызларның тәпиләре кыска булса да көчле икән. Әнә Кондызбай юан аяклары белән балчыкны чокып ала да тиз-тиз артка

ыргыта. Картның ярдәмчеләре – уллары балчыкка бер урынга өелергә ирек бирмиләр: аны керү-чыгу юлы булган тишектән еракkарак ыргыталар.

– Өйнең түр ягы гөмбәз рәвешендә булырга тиеш, – диде Кондызбай улларына. – Икенче өлешендә – керә торган якта – аш бүлмәсе урнашачак.

Кондызлар төзүче инженерлардан бер дә ким түгел. Барысын да алдан исәпләп һәм уйлап башкаралар. Кондызбай уллары Кыскатәпи, Юангәүдә һәм Киңмаңгай, торак җиткерүдә бар осталыкларын күрсәтеп, өн казуны бик кыска тоттылар. Әмма башкарасы эшләр шактый күп иде шул әле.

Өн казылып беткәч, Юангәүдә белән Киңмаңгай инеш ярындагы таллыкта үскән юан чыбыкларны үткен тешләре белән кисә башладылар. Тешләре таза икән, балтаң белән пычкың бер читтә торсын! Чыбыклар киселеп беткәч, кондызлар аларны су юлы белән өнгә ташырга керештеләр.

Суда аларның башлары гына күренә диярлек, ә авызларына капкан чыбыклар зур-зур мыекларны хәтерләтә иде. Өй турысына җиткәч, төзүчеләребез кинәт күздән югалдылар: су төбенә чумганнар икән.

Кондызбай улы Кыскатәпи белән бергәләп, чыбыкларны өн эченә ташып, торакның түр як диварларын ныгытырга, тал чыбыклары белән үрергә керешә. Шулай әкренләп өн эче әзер булды.

– Хәзер диварларны кызыл балчык измәсе белән сылыйсы гына калды, – диде Кондызбай карт. – Сез, улларым, каршы як яр буендагы таллыкка барыгыз. Аның янәшәсендә кызыл балчыклы яр булыр, шуннан өйгә балчык ташыгыз.

– Балчыкны ничек итеп алып кайтабыз соң? – дип сорады Кыскатәпи.

– Аны авызга тутырып ташырга кирәк, улым, – диде әтисе.

Яшь кондызлар, дәррәү килеп, өн тишегенә атылдылар, бераздан су өстенә калыктылар һәм, ярыша-ярыша, каршы як ярга таба йөзеп киттеләр.

Күксу инешенең елгага кушыла торган урынын кондызлар бик күп еллар элек буып куйганнар иде. Инеш суы тиешле биеклеккә күтәрелгәч, алар биредә үзләренә йорт җиткерделәр.

Кондызбай улларын түземсезлек белән көтеп алды. Алар өн эчендә күренүгә, ул:

– Озак көттердегез. Әллә берәр бәлагә юлыктылармы икән дип борчыла башладым, – диде.

– Авыз тулы балчык белән йөзүе җиңел түгел икән, – диде Кыскатәпи һәм түр якка узды.

Яшь кондызлар, балчыкны торакның урта бер җиренә бушатып, яңадан ярга юнәлделәр. Алар көне буе диярлек шул эш белән мәшгуль булдылар. Әтиләре исә диварларга беркетелгән чыбыкларны янә бер тапкыр тикшереп чыкты, купканнарын кабат ныклап урнаштырды.

– Менә хәзер барысы да тәртиптә, – диде ул үз-үзенә.

Кондызлар бүген йокларга иртә яттылар. Шулай булмыйча, көне буе эшләп, бик арганнар иде. Бигрәк тә Кыскатәпи талчыккан.

Икенче көнне иртүк йокыдан торып, тамак ялгап алгач, кондызлар тагын эшкә тотындылар. Аш бүлмәсенә күп итеп балчык ташыдылар.

Төштән соң тау булып өелгән балчыкны изә башладылар. Эш башлаганчы, Кыскатәпи:

– Әти, балчыкны нәрсә белән, ничек изәргә соң? – дип сорады.

– Улым, син балчыкны алгы аякларың белән бута. Су җитмәсә, авызыңа кабып, аны буадан ташы. Балчыкны бит суда яхшылап изәргә кирәк.

Яшь кондызлар, әтиләре өйрәткәнчә, инештән су ташып, алгы тәпиләре белән измә әзерләргә керештеләр. Әллә бу эштән кызык табып, әллә кәефе күтәрелеп, Кыскатәпи җырлап җибәрде:

Әти сайлады ип урын,
Өйнең салабыз матурын.
Бергә эшләгәч күңелле,
Хезмәт күтәрә күңелне.
Чапыр-чопыр китерәбез

Һәм балчыкны изәбез.
Без баскан саен үзләнә
Кызыл балчык измәбез.

Кыскатәпигә Юангәүдә белән Киңмаңгай да кушылдылар:

Без баскан саен үзләнә
Кызыл балчык измәбез.

Кондызбай, улларына ияреп, җырны үзенчә сузды:

Юангәүдә булгандыр,
Киңмаңгай да уңгандыр,
Кыскатәпи сынатмас –
Эш сөйгәннәр тик ятмас.
Ташып тора көчебез,
Гөрләп бара эшебез.
Үзле булды измәбез,
Җитәр, бүтән измәгез!

Алар, измәне бер урынга өеп, өй диварларын сылый башладылар. Кондызларның киң тәпиләре измә сылар өчен генә яраклашкан диярсең, Кондызбай белән Юангәүдә түр якка, Киңмаңгай белән Кыскатәпи аш бүлмәсенә тотындылар. Кондызбай карт яхшы эшли, чыбыкларны да оста яшерә. Измә катламы астында алар күренми дә диярлек.

Юангәүдә дә сер бирмәскә, әтисе кебек төгәл эшләргә тырыша. Ни дисәң дә, Кондызбай улы бит ул.  Кыскатәпи исә, шул арада әтисе янына килеп, аның эшенә күз төшерә, аннары үз ягындагы диварларның тигез сыланмаган урыннарын шомартып куя.

Кояш офыкка иңгәндә, Күксу осталары, түр як һәм аш бүлмәсе диварларын сылап бетереп, тамак ялгарга булдылар.

– Бүгенгә җитәр. Иртәгә дәвам итәрбез, – диде Кондызбай. – Хәзер буада юынып, таллыкка ашарга барырбыз.

Кондызлар, юынып, чистарынып алгач, яр буендагы таллардан һәм үләннәрдән авыз иттеләр. Аннан кире суга атылдылар. Авыр эш көненнән соң тәннәрен язып, бераз йөзеп уйнап алдылар. Өйләренә алар караңгы төшкәндә генә кайтып керделәр. Барысы да бергә җыелгач, Кондызбай әйтте:

– Әниегез белән икебезгә генә өй җиткерәсе булса, җәйдән алып кара көзгә чаклы изаланырга туры килгән булыр иде, ярый әле сез бар. Менә хәзер яңа йортлы да булачакбыз. Шуңа куанып бетә алмыйм. Сезгә, оланнар, бик зур рәхмәт. Тырышасыз, булсын дип эшлисез. Моннан соң да бер-берегезгә ярдәмчел булыгыз, матур яшәгез.

– Рәхмәт, әти, киңәшләреңне истә тотарбыз, – диделәр яшь кондызлар.

Кыскатәпи исә өстәп куйды:

– Яшисең килсә, селкенергә, барысына да өлгерергә кирәк икән, әти. Өлкәннәр белмичә әйтми алар.

Икенче көнне кондызлар эшне кыска тоттылар: алгы бүлмә диварларын да измә белән сыладылар, керү-чыгу тишеген дә ныгыттылар. Осталар инештән вак таш ташып, шуның белән түр як һәм аш бүлмәсе идәннәрен түшәделәр. Ак таш җәйгәч, өй эче яктырып киткәндәй булды.

Өй әзер булгач, Киңмаңгай бер тәкъдим ясады:

– Кышлыкка дигән азыкны да әзерләп куйсак, шәп булыр иде, әти. Күмәкләшеп тотынсак, бу эшне тиз башкарып чыгарбыз.

– Әйбәт тәкъдим, ләкин ашыкмыйк әле. Азык әзерләүне сентябрь башына калдырып торыйк. Сез дә ял итеп алыгыз, үз мәшәкатьләрегез дә бардыр. Аннан соң яңа өй эче дә ул вакытка кадәр кибәр.

– Ярый, без риза, – диде Киңмаңгай. – Алайса, азык әзерләүне көз башына чаклы калдырып торабыз.

Яшь кондызлар, әтиләре белән саубуллашып, кайтыр якка – инешнең түбән агымына юнәлделәр.

Кондызбай белән Кондызбикәнең яңа өй җиткерүләренә һич тә гаҗәпләнәсе юк. Кондыз халкында шундый йола яши: өлкәннәр өйләрен яшь парларга – яшь гаиләләргә калдыралар. Менә Кондызбай да, ата-баба йоласына тугры калып, үзенә яңа йорт салды, калган гомерләрен карчыгы белән яңа йортта кичерәчәкләр.

# БӘЛӘКӘЧ ТИЕНГӘ ДӨНЬЯ ТАР

Август ае тәмамланырга инде күп калмады. Төннәрен салкынча булса да, көннәр җылы тора. Әнә бүген дә кояш шактый югары күтәрелгән. Талгын гына җил исә. Су өсте көзгедәй ялтырый. Буа култыгында үскән сары төнбоеклар күптән юкка чыккан, аларның бары киң, түгәрәк яфраклары гына су өстендә чайкала. Яр буенда утырган нарат, чыршы агачлары, яшел күлмәкләре белән көязләнеп, су өстенә төшкән шәүләләренә карап сокланалар.

Шушы хозурлыктан тәм табыпмы, әллә яшь чакларын искә төшерепме, Кондызбай белән Кондызбикә суда уйнап алырга булдылар. Рәхәт аларга. Шулай булмыйча, җәйнең матур көннәрендә үк яңа өннәре әзер булды. Тормышлары имин бара. Уллары да әти-әниләренә ярдәм итәргә ашкынып торалар.

– Бәхетле картлык кичерәбез, – диде Кондызбай.

– Әйе, шулай, – диде Кондызбикә басынкы һәм йомшак тавыш белән. – Яңа өйнең рәхәтен күрергә насыйп булсын.

Яр читендәге усак агачы ботагында утырган пумала койрыклы бәләкәч тиен кондызлардан күзен алмады, хәтта алардан бераз көнләшеп тә куйды:

– Эх, мин дә алар кебек йөзә белсәм, суга чумып, су асты дөньясы белән танышыр идем. Кондызларга рәхәт тә, күңелле дә: телиләр икән, җирдә йөриләр, телиләр икән, суда йөзәләр. Алар мин күрмәгән, мин белмәгән җан ияләре белән дә таныштыр әле. Ә минем бар белгәнем – ботактан ботакка сикерү, ерткыч кош-корттан һәм усал селәүсеннән саклану.

Бәләкәч иң аскы ботакка төшеп утырды. Аннары игътибарын су үсемлекләренә юнәлтте. Буа төбендә валлиснерия, кабомба, тагын әллә нинди үсемлекләр җай гына чайкалып утыралар иде.

– Нинди матур үләннәр, – диде Бәләкәч, сокланып. – Әйтерсең су төбенә яшел, ак, сары һәм кызгылт чуерташлар сибелгән.

Бала тиен, судан күзләрен алмыйча, тирән итеп көрсенде. Аннан түзмәде, каршысына таба йөзеп килгән пар кондызга эндәште:

– Су белән җирне бердәй күреп яшәгәч күңелледер ул?! Сезгә суда да, җирдә дә куркыныч түгел.

– Без дөньяга шулай яратылган инде, – дип елмайды Кондызбай. – Син кечкенә әле. Үскәч, сиңа да урман киңәер. Әллә кайларга барып җитәрсең, үз гомереңдә күп нәрсәләр күрерсең. Һәр җан иясенең үз көне, үз тормышы бар. Син шуңа риза бул, тиен баласы!

Бәләкәч, ботактан ботакка сикерә-сикерә, урман эченә кереп югалды. Кондызлар алга таба йөзеп киттеләр. Үзләре яшәгән өннәре янына килеп җиткәч, янәшәдә үсеп утырган су кәбестәсеннән авыз иттеләр.

– Матур урында яшибез бит, – диде Кондызбикә. – Бу инеш табигатьнең иң гүзәл почмагыннан агадыр.

– Әйе, матур җирдә яшибез, – дип, Кондызбай яр читенә үрмәләде.

## САГЫНДЫРГАН КУНАК

Төшке ашны ашап утырганда, өнгә кечкенә кондыз баласы килеп керде. Кондызбай аңа текәлеп карады да сузынкы тавыш белән:

– Оныгым Карасырт килгән икән бит, менә яхшы булган, – диде һәм нәни кондызны кочагына алды.

– Сезгә кунакка килдем, бабакаем, әбекәем. Өегезне котлап, үзегезгә күчтәнәч тә алдым. Әнием тукранбаштан күмәчләр пешергән иде. Яңа йортта бәхетле гомер кичерегез.

– Һай, рәхмәт яугыры, – диде Кондызбай.

– Әти-әниең, туганнарың исән-сау гына торалармы? – диде әбисе, оныгын кочаклап. – Сагынып беттек үзегезне. Бу арада сезгә барганым юк шул. Юангәүдә улым гаиләсендә кунак булдым. Карасырт, буйга да үсеп киткәнсең ләбаса! Күз тимәсен!

– Улым, тамагың да ачкандыр. Тәмле ризыклар белән сыйлыйм әле үзеңне. Сез яшәгән җирдә камыш белән җикән генә үсә. Ә менә

бездә су кәбестәсе, төнбоек, комай, күрән һәм башка үсемлекләрдән авыз итәргә була, – диде Кондызбай һәм суга сикерде.

Бераздан ул су өстенә калыкты. Аның авызында су кәбестәсе, комай һәм тагын берничә төрле үлән бар иде. Кондызбай, ярга чыккач та әле, үзәнлектән күрән җыйды. Бары шуннан соң гына кайтыр юлга чыкты. Аның оныгын тизрәк шатландырасы килә иде.

– Менә безнең як ризыкларыннан да авыз итеп кара, улым, – дип, Карасырт алдына бер кочак сый-нигъмәт китереп куйды ул, кайтып кергәч тә.

Карасыртның мондый үләннәрне ашаганы юк иде, шуңа күрә:

– Бу үсемлекләр бик тәмле икән. Телеңне йотарлык, – дип күчтәнәчләрне шатлана-шатлана ашады.

Шул рәвешле бала кондыз әбисе белән бабасында өч көн кунак булды. Дүртенче көнне исә, рәхмәтләр әйтеп, үз өенә кайтып китте.

# КАРАСЫРТ ҺӘМ СОРЫБАШ

Беркөнне Карасырт, кичке ашны ашаганнан соң, бераз уйнап кайтырга булды. Бу хакта әнисенә әйткәч:

– Балам, сак бул! Уяулыгыңны югалтма! Камышлык тирәсендә усал чуртан яшәгәнен беләсең. Ярга чыгып йөрмә, бүре яки төлке авызына эләгерсең... – диде ана кондыз.

Аның сүзләренә Карасырт артык игътибар бирмәде. Ул күңеле белән инде күптән инеш буенда иде.

Су өсте тып-тын. Карасырт тирә-якны күзәтеп чыкты. Аннан ашыкмый гына йөзеп китте. Кинәт аның каршысына бер кечкенә җәнлек килеп чыкты һәм, куркып, яр кырыенда үскән үләннәр арасына кереп качарга уйлады. Карасырт аңа:

– Әй, кем дип дәшим үзеңә, нигә миннән шүрлисең? – диде. – Мин беркемгә дә тимим.

– Син зур бит, йә мине тотып ашарсың.

– Юк, мин андый заттан түгел, үлән, агач кайрылары белән генә тукланам.

– Син кем буласың соң?

– Мин кондыз булам. Исемем – Карасырт. Ә син кем?

– Мин – су күсесе малае Сорыбаш. Безне «ондатра» дип тә йөртәләр.

– Менә таныштык та, – диде Карасырт, куанып.

– Әйдә куышлы уйныйбыз.

– Куышлы уйнарга синең башка дусларың юкмыни?

– Дусларым күп минем, тик менә синең белән дә дуслашасым килә.

– Ярый, мин риза.

Алар, үлән сирәк үскән урынны сайлап, әкрен генә йөзеп киттеләр. Күсе малае Сорыбаш бик тере икән: камышларны ялт-йолт әйләнеп уза.

– Карасырт, куып тот мине!

– Син шәп йөзәсең, Сорыбаш. Мин алай кызу барырга өйрәнмәгән. Кара әле, Сорыбаш, әйдә син минем аркама менеп утыр, үзеңне көймәдә йөзгәндәй хис итәрсең.

– Шәп була бу, утырам, әлбәттә, – диде күсе малае, – уеныбыз да кызыклырак булыр.

Сорыбаш кондызның аркасына менеп кунаклады, һәм алар шул рәвешле алга таба йөзеп киттеләр.

– Карасырт, син дә кызу йөзәсең бит. Әнә аркаңа чытырдап ябыштым. Егылып төшмәсәм ярый инде.

Күсе малае тагын нәрсәдер әйтергә уйлаган иде, кинәт авызын ачкан килеш өнсез калды. Аларның каршысына явыз чуртан йөзеп килә иде. Сорыбаш бар тавышына кычкырып җибәрде:

– Карасырт, каршыбызга чуртан йөзеп килә! Ул хәзер безне кабып йотачак. Тизрәк ярга сикер!

Чуртанны кондыз малае да күреп алды һәм уктай ярга атылды. Авызын ачкан килеш, пычкы тешләрен ялтыратып, чуртан юан камышка килеп төртелде. Ул да булмады, ерткыч ялт итеп борылды да, камышны әйләнеп, ярга таба ашыкты. Ләкин Сорыбаш белән Карасыртны эләктерә алмады.

Җәнлекләр бик озак куркышып утырганнан соң гына сөйләшерлек хәлгә килделәр.

– Әллә берәр җиреңне авырттырдыңмы, Сорыбаш?

– Юк, – дип пышылдады «җайдак».

Күсе малаеның бу кадәр курыкканы юк иде. Әле һаман да йөрәге леп-леп тибә, тәне дер-дер килә.

– Ярый вакытында күреп өлгердек. Элек тә бу балык белән очрашканым бар иде. Ул бик күп күселәрнең гомерен өзде. Шуңа күрә без чуртаннанерактарак йөрергә тырышабыз.

– Мин аңардан курыкмыйм, – диде Карасырт. – Тешләрем бик үткен. Чуртанны эләктерсәм...

– Әй, Карасырт, мактанма әле! Чуртанга эләксәң, исән-сау котыла алмассың.

Карасыртның күсе малае алдында үзен батыр, гайрәтле итеп күрсәтәсе килде бугай. Ә кем белә, бәлки, ул чыннан да көчле һәм кыюдыр. Әнә бүгенге көнгә кадәр бер генә кондызның да чуртан авызына эләккәне юк бит.

# ҖОФАР МАЛАЕ КЫЛЫЧКОЙРЫК

Карасырт бүген кичке якта тагын уйнарга чыкты. Буа култыгына таба йөзгәндә, яр буенда утырган җофарны абайлап алды ул. Кондыз малаеның мондый җәнлекне беренче күрүе иде. Ул су читенә килеп туктады да әлеге җәнлеккә дәште:

– Син кем буласың? Бер дә очратканым юк үзеңне.

– Мин – җофар улы Кылычкойрык. Шушы инеш-буада яшим.

– Ә мин – кондыз улы Карасырт. Карале, койрыгың чыннан да кылыч шикелле икән.

– Андый койрык белән суда йөзүе җиңел. Руль кебек ул.

– Ул яктан минем койрык та әйбәт анысы. Салмак кына өскә-аска уйнаклатып, төрле тирәнлектәге суда йөзәргә була.

– Алайса, без бер-беребезгә охшаган икән. Әмма аермалы якларыбыз да бар. Минем койрык кылычтай, ә синеке – җәлпәк. Без гәүдәгә дә кечерәк, борыныбыз хортумга охшаган. Андый борынны су өстенә чыгарып, без һава сулыйбыз, ә гәүдәбез су астында кала. Хортум җофар халкына дошманнардан сакланырга ярдәм итә. Безне беркем дә күрми.

Карасырт белән Кылычкойрык озак сөйләштеләр, дуслашырга да өлгерделәр. Бераздан җофар улы:

– Миңа өйгә кайтырга вакыт, – диде. – Өйдәгеләр югалтканнардыр.

– Борчылма, дустым. Минем әле сиңа үз өемне күрсәтәсем килә. Әйдә безгә кунакка. Аннары минем әти белән әни сине озатып куярлар. Алар бу инешне яхшы беләләр.

Ике дус Карасыртларга кайтып җиткәндә, кояш баткан иде инде.

– Бу – җофар малае Кылычкойрык, – дип таныштырды әти-әнисен Карасырт. – Мин аны үзебезгә кунакка чакырдым. Әнием, соңыннан син аны өенә кадәр озатып куярсың инде. Син бит аларның кайда яшәгәннәрен беләсең.

– Әйе, минем Җофарбайларда булганым бар, – диде Уңганбикә. – Озатып куярмын.

Бераз уйнагач, Уңганбикә җофар малаена дәште:

– Кылычкойрык, болай ярамас, әти-әниең борчыладыр. Әйдә өеңә илтә барам.

Атлый торгач, алар Җофарбай торган өнгә дә җиттеләр. Өн каршысындагы камышлыкта ук аларга Кылычкойрыкның әнисе очрады. Улын эзләргә чыккан икән ул.

– Кылычкойрык бездә кунакта булды, – диде Уңганбикә. – Менә озата килдем үзен.

– Тиктормас бала шул ул. Бер өйдә утырмый, кая да булса китеп югала.

Аннан, Кылычкойрыкка борылып:

– Улым, мин сиңа өн тирәсеннән ерак китмә дип йөз тапкыр әйткәнмендер. Ә син һаман үзеңнекен итәсең. Өлкәннәр сүзен колагыңа да элмисең! – диде әни кеше һәм улын өйгә кертеп җибәрде. – Бар белгәне уен да уен. Озата килүең өчен рәхмәт сиңа, Уңганбикә!

Ике әни бер-берсенә исәнлек-саулык теләп аерылыштылар. Уңганбикә кире үз өйләренә кайтып китте.

## ТӘВӘККӘЛ КАМАҖАН

Эңгер-меңгер вакыт җитеп килә иде. Күктә йөзгән берән-сәрән болытлар алсу төскә манчылган. Кинәт урман эченнән мәче башлы

ябалакның эчпошыргыч, ямьсез тавышы ишетелде. Башка кошкортлар куркышып, сагаеп калдылар.

Әнә шундый бер вакытта Уңганбикә өенә кайтып барган җирдән камага юлыкты. Аның, бу җәнлек белән аралашканы булмаса да, күргәне бар иде, шуңа күрә якын танышлар кебек елмаеп исәнләште. Аннары:

– Ни эш бетереп йөрисең, Камаҗан? – диде.

– Сез торган якларда сәяхәт кылып йөрим әле. Елгадан килеп, инешегезне, буагызны күрергә, кондызларның нинди эшләр майтарганын белеп кайтырга ниятләгән идем.

– Сәфәрең изге икән, Камаҗан. Тик соңга калгансың бит. Көн төнгә авыша лабаса.

– Соңардым шул. Менә икенче көн инде акай күзле чуртанны эзәрлеклим. Эләктерергә исәбем үзен. Сезгә дә тынгы бирмидер ул.

– Әйе, ул ерткыч безнең буада күптән чуала. Билгеле, юкка түгел, су күселәренә көн күрсәтми. Ничек биздерергә икән аны? Һич уйлап таба алмыйм.

– Хәзер инде караңгы төште. Бу эшне иртәнгә калдырып торыйк. Син, Уңганбикә, иртүк буага чык. Чуртанны эзләп табып, һичшиксез куып җибәрергә кирәк.

Шулай килешеп, аларның һәркайсы үз юлы белән китеп барды.

Икенче көнне Камаҗан һәм Уңганбикә таллык янәшәсендәге камышлыкта очраштылар. Камаҗан шүрли торган заттан түгел. Гәүдәгә дә зур, көчле дә. Аңа ышанырга була.

Чуртанны тиз эзләп таптылар. Ул камыш төбенә яшеренгән иде. Беренче булып балыкка Камаҗан ташланды. Үткен тешләре белән аның койрык йөзгечен җәрәхәтләде. Тегесе, дугадай бөгелеп, пычкы кебек үткен тешләрен күрсәтте. Тик Камаҗан артка чигенмәде, «нишләр икән бу?» дип, бермәлгә туктап калды. Уңганбикә дә, авызын зур ачып, казыктай алгы тешләре белән ерткыч балыкка һөҗүм итте. «Бу алышның ахыры минем өчен үкенечле булыр, ахры» дипме, чуртан шарлавык ягына элдерде. Кама белән кондыз аны җанфәрманга куа киттеләр. Качып котылу өчен чуртанга бары буа

читеннән аккан шарлавык буйлап зур елгага юл тоту чарасы гына калган иде.

Әнә шулай Камаҗан белән Уңганбикә ерткычның кирәген бирделәр. Бу хәлдән соң чуртан буада башка күренмәде. Күксу инешен бөтенләйгә онытты бугай ул.

# КӨЗГЕ МӘШӘКАТЬЛӘР

Сентябрь ае да ишек какты. Көннәр кояшлы һәм җылы тора. Кондызларның кызу урак өсте хәзер. Кышка җитәрлек азык әзерлисе бар. Бу эш күп көч сорый шул. Кондызлар моны яхшы беләләр. Сентябрьнең башланып китүе генә булды, дәррәү эшкә тотындылар.

Кондызбай һәм Кондызбикә дә, җиңнәрен сызганып, азык әзерләргә керештеләр. Улларына да хәлне аңлаттылар:

– Җәйге көннәрдә җаныбыз теләгән ризыкны ашадык, мохтаҗлык кичермәдек. Сез инде беләсез: кыш көне җир кар астында йокыга тала. Шуңа күрә без җылы язга җитәрлек азык әзерләргә тиеш булабыз. Безнең алда тал һәм усак ботакларын кисү, ашарга яраклы агач кайрыларын каезлау, юан булмаган агачларны аударып, аларны тураклап, өйгә ташу эшләре тора.

– Без эшкә һәрвакыт әзер! Куркып тормыйбыз! – дип җавап бирделәр Кондызбай уллары.

Кондызлар җәй көннәрендә ояларыннан кичке якта гына чыгып йөриләр иде. Ә хәзер аларны көндез дә күрергә була. Берсе ерактагы таллыкка яки урманга бара, икенчесе инеш буйлап яшь чыбык, кыска итеп киселгән усак һәм тал пүләннәрен ташый.

Кондызбай да уллары Юангәүдә, Киңмаңгай һәм Кыскатәпи белән урманга юнәлде. Алар буа култыгы янындагы куе агачлыкка керделәр. Анда элек-электән усаклар үсә иде.

– Улларым, башта шушы агачларны кисегез, – диде Кондызбай. – Аннары аларны утын кискән кебек тураклагыз.

Яшь кондызлар үткен тешләре белән агачларны төптән кимерә башладылар. Урман шыгыр-шыгыр китереп агач кимергән

тавышларга күмелде. Шактый озак тырышканнан соң, усаклар берәм-берәм җиргә аудылар. Кондызбай исә барысын карап, киңәшләр биреп, тикшереп йөрде.

– Яшь ботакларны өйгә ташый башласак та ярар. Кыскатәпи, бу эшне сиңа йөклим. Юангәүдә белән Киңмаңгай агач кәүсәләрен тураклар. Ә мин әзер пүләннәрне су читенә ташырмын.

Кыскатәпи, тешләре белән берничә ботакны эләктереп, буа култыгына юнәлде. Аннан сөзәк ярдан суга төште һәм әтисе өненә таба йөзә башлады.

Өйдә Кыскатәпине әбисе каршы алды. Инде зур яшьтә булуына карамастан, балаларына ярдәм итәргә килгән икән. Ул оныгы алып кайткан ботакларны шунда ук аш бүлмәсенә ташый да башлады. Кыскатәпи исә кире урманга китте.

Әйләнеп килгәндә, «урман кисүчеләр» агач ботакларын һәм пүләннәрне яр буена ташырга җыеналар иде.

– Улларым, – диде Кондызбай, – безне иртәгә дә шушы эш көтә. Аннары үзегезгә дә азык әзерлисе булачак. Барысын да бергә башкарып чыгыйк. Күмәк эшләнгән эш тиз бетә ул.

– Әти, без синең белән килешәбез, – дип сүз башлады Юангәүдә. – Бергәлектә – берәгәйлек. Кара әле, әти, мин, гаиләм белән бергәләп, агач ташый торган канауны да чистартып куйган идем.

– Монысы өчен аеруча рәхмәт сиңа, улым! Йомры пүләннәрне коры җир буйлап сөйрәү җиңел түгел шул.

Юангәүдә бу канауны кайчандыр әтисе белән үзе казыган иде. Моннан ике ел элек бугай.

Алар дәррәү ботак ташырга керештеләр. Бераздан пүләннәрне, тәгәрәтеп, яр башына китерделәр. Бу эш кондызлар өчен бик җиңел булмады, чөнки пүләннәр авыр да, зур да иде. Ниһаять, аларны суга төшереп, кайтыр юлга чыктылар. Җил әтиләре яшәгән өн ягына исә, шуңа күрә йөзеп баруы җиңел иде.

Әнә шулай берничә көн эшләгәннән соң, Кондызбай белән Кондызбикәнең тормышлары түгәрәкләнде: алар яңа йортлы да һәм язга чаклы җитәрлек ризыклы да булдылар.

– Оланнардан уңдык, – диде ата кеше. – Эшне белеп, җиренә җиткереп башкаралар. Бик өлгерләр. Аннан соң әле үземдә дә көч-куәт җитәрлек икән.

Ул шатлыгыннан җырлап җибәрде:

Һәй, бирешмә, Кондызбай,
Мине хаста күрмәсен.
Безнең туган якларда
Кайгы-хәсрәт йөрмәсен.
Кондызбикәм, йөз яшә!
Йөз яшәгән күп түзгән,
Урманнарны күп гизгән,
Елга-күлдә күп йөзгән.

Әйе, Кондызбайның кәефе яхшы иде бүген.

Икенче көнне Кондызбай, кояш күтәрелгәндә, Юангәүдә яшәгән йорт янына килеп җитте. Көн матур. Яр буен яңгыратып, кошлар сайрый. Кондызбай тип-тигез су өстен күзәтә башлады һәм ярга таба йөзеп килүче бер төркем кондызларны күреп алды.

– Болар оныгым Карасырт белән киленем Уңганбикә түгелме соң? – диде ул. – Әйе шул, ә алар артыннан йөзеп килүчеләре кемнәр икән?

Чыннан да, алдан йөзеп килүчеләр Уңганбикә һәм Карасырт иде. Авызларына бер кочак чыбык капканнар. Алар артыннан Юангәүдә белән улы Җәлпәккойрык йөзә.

– Эшне бигрәк иртә башлагансыз, – дип каршы алды аларны Кондызбай.

– Әти, үзең беләсең, безнең халык төнлә йөрергә күнеккән, – диде Юангәүдә. – Көндез өйдә, төнлә буада, Күксу буйларында булабыз.

– Дөрес, улым. Кондыз халкы шулай яши инде ул. Көз көне азык әзерләгәндә генә, көн-төн белән исәпләшмибез. Тормыш шулай куша.

Тиздән бирегә Киңмаңгай белән Кыскатәпи дә килеп җитте, һәм Кондызбайның зур гаиләсе янә эшкә тотынды.

Кондызлар шул рәвешле, чиратлашып, башта бер гаиләгә, аннан икенчесенә кышлык азык тупладылар.

# АФӘТ КИТЕРГӘН ЯҢГЫРЛАР

Октябрь ае тәмамланганда, салкын яңгырлар ешаеп китте. Берничә көн туктамый чиләкләп койганнан соң, буада су күзгә күренеп артты. Кондызлар кайгыра башладылар: буаны су алып китсә, эшләр харап.

Юкка борчылмаганнар икән. Буа-плотинаның суүткәргеч канавы ташуга, көчле агымга чыдамады. Яңгыр суы канаудагы ташларны һәм чыбыкларны агызып алып китте. Кызыл балчык катыш пычрак су, куәтле ташкынга әверелеп, елгага юл алды. Буадагы су күзгә күренеп кимеде.

Ташу кондызларның чыбык-чабыктан җиткерелгән җәйге өйләрен дә агызып алып китте. Су җәнлекләренең җәй буена тырышып эшләгәннәре ун-унбиш минут эчендә юкка чыкты. Судан калкып күренеп торган кондыз өннәре әйтерсең Күксу инешендә беркайчан да булмаган.

Яңгыр икенче көнне төшкә таба гына туктады. Тик буа булган урын сай инешкә әверелде шул. Кондыз өннәренең керү-чыгу юллары – тишекләре – су астында түгел, ә коры ярда ачылып калдылар. Бу хәл кондызлар өчен зур куркыныч тудырды, чөнки ул тишекләрдән өнгә бүре кебек ерткычлар керергә һәм һөҗүм итәргә мөмкин. Әнә шулай Күксудагы кондыз халкы ут йотып тора башлады.

Кондызбай инженер Кондызби өенә юл тотты. Ул бу хәлләр турында сөйләшергә, ниндидер чишү юлын табарга тели иде.

– Мондый афәткә дучар булырбыз дип һич тә уйламаган идем. Плотинаны төзәтмәсәк, яши алмаячакбыз, – диде Кондызби.

– Мин дә шул фикердә, – дип дәвам итте Кондызбай. – Буаны элеккесенә караганда да ныклырак, чыдамрак итеп эшләргә кирәк.

– Җәйге өйләрсез дә яшәп булмый. Аларны тиз арада җиткерә, төзи алырбызмы? Гел караңгы өндә – җир астында көн үткәреп булмас бит. Көн яктысына карап, җәйге өйдә ял итүе үзе бер рәхәт.

– Буаны төзеп бетереп, анда җитәрлек су җыелса, өйләрне һичшиксез ясарбыз, – диде Кондызбай. – Тормышыбыз янә үз җаена кайтыр.

## КҮМӘК КӨЧ ТАУ КҮЧЕРЕР

Өлкән кондызларның барысы да инженер Кондызби һәм - Кондызбай янына җыелды. Һәркайсы үз фикерен җиткерергә ашыкты.

– Барлык гаиләләр дә кышлык азык запасы туплады инде, – дип сүз башлады Кондызбайның күршесе аксакал Кондызбаба. – Шуңа күрә һәркем буаны яңарту, аны теләсә нинди ташуга каршы тора алырлык итеп төзәтү турында уйларга тиеш.

– Кондызбаба хак әйтә. Безгә бүгеннән үк эшкә керешергә кирәк! – диделәр өлкәннәр бертавыштан.

– Тик безгә өстәмә ярдәм кирәк булачак, – диде инженер. – Минә Кондызбай ага да шул фикердә.

– Кемнәрне чакырабыз соң?

– Зәңгәр күлдә яшәүче күршеләребезне, – диде инженер.

Кондызбаба, каршында басып торган буадашларын күздән кичереп:

– Йә, җәмәгать, күршеләргә кемне җибәрәбез? Илче вазифасын башкарып чыга алырлык кеше кирәк безгә.

– Кондызбайны җибәрәбез. Аннан да яхшырак илчене таба алмабыз, – диделәр кондызлар бертавыштан.

Кондыз халкы әнә шундый фикергә килде һәм илчегә хәерле юл теләде. Ә Кондызбай шул көнне үк Зәңгәр күлгә юл тотты.

Күксулыларның эшкә яраклы барлык яше-карты исә буа ерылган якка таба ашыкты. Анда инженер Кондызби болай диде:

– Безгә плотинаны астан буйдан-буйга таш белән ныгытырга, төбен киңәйтергә кирәк. Шулай эшләгәндә генә, буа ышанычлы булачак. Ә эшкә килгәндә, өйрәтәсе юк, барысын да беләбез.

– Әйе-әйе, без моны булдырабыз! – диделәр кондызлар.

– Хәзер һәркем, булдыра алганча, яр буеннан таш алып килсен, йөген буа төбенә бушатсын. Ә ташчыларыбыз бар осталыкларын күрсәтсеннәр, кызыл балчыкны ташып торырбыз.

Инженерның әмерен ишетүгә, кондызлар дәррәү эшкә тотындылар. Ул арада Зәңгәр күл кондызлары да күршеләренә ярдәмгә килеп җиттеләр. Күксулылар аларны шатланып каршы алдылар.

Төш җиткәндә, буа күзгә күренеп яңара башлады. Инженер Кондызби эшнең барышы һәм сыйфаты белән һәрдаим кызыксынып йөрде. Бер төркем төзүчеләр, урманнан чыбык ташып, аны буаның ян-ягына утыртып чыгарга, ташларны кызыл балчык белән сылап, плотина өстенә җәергә керештеләр.

– Болай кызу эшләсәк, буаны салкыннарга кадәр өлгертәчәкбез, – диде инженер. – Иң авыры буа ерылган урын булачак. Бу җирне эшләргә керешкәнче, таш, кызыл балчык, агач кәүсәләрен һәм чыбыкларны җитәрлек итеп әзерләргә тиешбез.

– Шулай ук тиз дә эшләргә тиешбез! – дип җөпләде аны Кондызбай. – Без шарлавык аккан төштә өлгерлектә һәм осталыкта имтихан тотачакбыз.

Эшли торгач, кич тә җитте. Күренеп тора: кондызлар бик арганнар. Инженер, моны күреп:

– Хәлдән тайган төзүчедән сыйфатлы эш көтеп булмый, – диде. – Бүгенгә җитәр! Өйләрегезгә кайтыгыз. Ял итегез. Ә иртәгә иртүк нәкъ шушы урында – буа башында җыелырбыз. Ярдәмгә килгән күршеләребезне өегезгә кунакка чакырырга да онытмагыз!

Өн хуҗаларының һәркайсы Зәңгәр күл кондызларын үзләренә чакырды. Кондызбай да ике төзүче кунакны ияртте.

## КУНАКЛАР

Өнгә керүгә үк, Кондызбай кунакларны түргә чакырды.

– Өең иркен һәм матур икән, – диде Ерыкирен. – Күренеп тора, аны әле генә өлгертеп яши башлагансыз. Игелеген күрергә насыйп булсын.

– Рәхәт яшәгез, – диде Елтыркүз.

– Теләгегез изге, рәхмәт сезгә, – дип, өн хуҗасы Зәңгәр күл кондызларын кичке ашка чакырды.

– Тәмле суүсемнәрдән авыз итегез, – дип кыстады Кондызбай кунакларны. – Иртәгәсе көнгә көч җыярга кирәк.

– Мондый афәтне беркемгә дә күрергә язмасын, – диде Ерыкирен. – Без бергәләп буаны кире үз хәленә кайтарырбыз.

– Шулай, – дип сүзгә кушылды икенче кунак. – Безне ярдәмгә чакырып дөрес эшләдегез. Хәлегез бит чыннан да начар. Өнгә керүчыгу юлларыгыз ачык. Бу бик куркыныч.

– Зәңгәр күлдә мондый хәлләрнең булганы бармы? – дип сорады Кондызбай.

– Юк, – диде Ерыкирен, – бездә су артмый да, кимеми дә диярлек. Чөнки күлебезнең бер читеннән инеш агып чыга. Нәкъ менә ул күлдәге суның күләмен тәртиптә тота.

– Алай икән. Сезнең күлдә камышлар да үсә. Урманы да шунда гына. Яшәү өчен менә дигән җир.

– Әйе, зарланмыйбыз, – дип куәтләде аның сүзен Елтыркүз. – Табигать безнең өчен бернәрсәне дә кызганмаган. Шуңа да тыныч яшибез, тамагыбыз тук.

– Без дә моңа кадәр әйбәт яшәдек, – диде Кондызбикә. – Хәзер генә...

Шулвакыт:

– Кондызбай ага, эчкә узарга мөмкинме? – дигән тавыш ишетелде.

– Рәхим итегез! Кем әле бу?

– Бу мин – Җофарбай. Хәлегезне белеп чыгыйм дидем. Әллә кунаклар да бар инде үзегездә?

– Әйе, болар – Зәңгәр күлдән килгән осталар. Безгә буаны төзәтергә ярдәм итәләр.

– Изге эш кылып йөриләр икән күршеләр. Рәхмәт яугыры үзләренә.

– Кондыз халкы бердәм ул. Алар бер-беренә яхшылык эшләргә ашкынып торалар. Күмәкләшеп эшли башласалар, бар җәнлекләрдән дә уздыралар, – дип җөпләде сүзен өй хуҗасы.

– Дөрес әйтәсең, Кондызбай, – диделәр кунаклар.

Җофарбай әңгәмәне икенчегә борды:

– Кондызбай, мин улым Кылычкойрыкны эзлим бит әле. Иртән үк чыгып киткән иде, шуннан бирле кайтканы юк. Аны күргәнең булмадымы икән дип сорамакчы идем.

– Беркөнне киленем Уңганбикә миңа улы Карасыртның җофар малае белән уйнавы турында сөйләгән иде. Шуннан башка бернәрсә дә белмим. Син, Җофарбай, улым Киңмаңгай өенә барып кара. Бәлки, Кылычкойрык минем оныгым Карасырт янындадыр.

– Алайса, мин Киңмаңгайларга китим әле. Бигрәк тиктормас булды шул, – дип, Җофарбай барысы белән дә саубуллашырга ашыкты.

– Минем оныгым Карасырт та шундый. Ашавын онытып, көннәр буе уйнап йөри ала.

Җофарбай чыгып киткәч, кондызлар йокларга яттылар. Таң белән торып эшкә барасы да бар бит.

# КҮКСУДА ЭШ КАЙНЫЙ

Көчле яңгырлар башка яумады. Кондызлар, яхшы һава торышыннан файдаланып, плотинаны элеккесенә караганда да ныклырак итеп торгыздылар. Бу эшне тәмамлап чыкканнан соң, алар буа суы биеклеген көйли торган канауны өр-яңадан төзи башладылар.

– Канауга таш түшәр алдыннан, яшь имәннәрне кисеп, казыклар әзерләргә кирәк, – диде инженер Кондызби. – Аларны канауның иңеннән-иңенә һәм буеннан-буена кагып чыгарбыз. Еш итеп кагылган казыклар ташларны урыннарында тотып торачак. Билгеле, бу – мәшәкатьле эш, тик соңыннан үзебезгә яхшырак булыр.

– Без эштән курыкмыйбыз! – диделәр кондызлар.

Бераздан төзүчеләр яр буендагы урманга юл тоттылар. Анда көнозын пычкы тавышларын хәтерләткән авазлар яңгырап торды. Кондызлар казыктай зур һәм үткен тешләре белән агачларны «кистеләр». Аннары бу агачлардан казыклар ясадылар.

Кечкенә кондызлар Карасырт, Көрәнарка һәм Юантәпи дә эти-әниләренә ярдәм иттеләр: киселгән агачларны ботаклардан арындырдылар, казык өчен әзерләнгәннәрен очлап тордылар.

– Яшьтән үк эш җаен белеп үссәгез, тормыш итәргә үзегезгә җиңелрәк булыр, – диде аталары.

– Әти, әзер казыкларны канау янына ташырга ярыймы инде? – диде Карасырт.

– Нигә ярамасын. Әйдә, улым, бар осталыгыңны күрсәт әле!

Бала кондыз бер казыкны янбашы белән ярга таба тәгәрәтә дә башлады. Бу шөгыль бик кызык булып тоелды аңа. Әйе, башкарган эш – яшәү, тормыш итү терәге. Әнә Көрәнарка казыкны тешләре белән ничек итеп очлый, хәйран калырсың. Көч куймыйча бернәрсәгә дә ирешеп булмый шул.

– Минемчә, казыклар бик очлы булырга тиеш, – диде Көрәнарка. – Аларны җиргә кагуы җайлырак булсын. Әтием дә минем эшемнән канәгать калыр.

Юантәпи дә ара-тирә туганына күз төшереп ала. Янәсе, мин Көрәнарка кебек булдыра аламмы? Ә нигә булдырмаска! Кондызлар тумыштан һәр эшнең җаен беләләр.

– Мин дә төшеп калганнардан түгел, – диде ул үз-үзенә. – Хәзер әзер казыкларны ярга тәгәрәтәм.

Төзү өчен кирәкле бар нәрсә канау янына ташылып беткәч, Күксу кондызлары инженер Кондызбинең карарын тыңларга җыелдылар.

Кондызби:

– Ә хәзер канау сузылган урынга казыклар кагарга керешегез! – дип боерык бирде.

Канауда кызу эш кайный. Ярдан һавага тузан күтәрелә, әйтерсең биредә бер-берсенә дошман ике гаскәр алышы бара. Көтмәгәндә, Күксу инеше буйлап җыр яңгырады:

Без – Зәңгәр күл кондызлары,
Ә без – Күксу осталары.
Күрше күршесен онытмас,
Күрше күршегә шик тотмас.
Как казыкны, әйдә как!
Казыклар нык утырсын!

Суүткәргеч канау да
Бирешмичә нык торсын!
– Булдырасыз, – дип, – кондызлар!
Күктә яна йолдызлар.
Кондыз алынса, эш уңа,
Төзүчеләр шат шуңа.
Бергәләп күтәрик тә
Салыйк әйдә ташын да!
Ташлар ятсын берегеп
Яңа канау башында.

Чыннан да, кондызларның эше гөрли. Төзүчеләр, су юлын ябып, калын итеп таш катламы түшәделәр. Буада арткан суны күреп, кондызларның да кәефләре күтәрелде. Ничә көн армый-талмый эшләгәннең нәтиҗәсе бит ул. Канау буа өслегеннән бераз түбән итеп ясалды, чөнки җыелган су шул канаудан агарга тиеш бит.

Ниһаять, эш тәмамланды. Кондызлар плотинаны тиз арада төзәтә алуларына бик шатландылар.

## ЗУР ТАНТАНА

Буа торгызуны башкарып чыкканнан соң, Күксуда зур тантана булды.

– Без бар киртәләрне дә җиңеп чыктык. Буа янә элекке хәленә кайтты! – диделәр Күксу кондызлары.

– Игелекле ярдәмнәре өчен күршеләребезгә мең-мең рәхмәт!

– Сезгә башка мондый бәлагә юлыгырга язмасын! – диделәр Зәңгәр күлдән килгән ярдәмчеләр.

Инженер Кондызби буаны торгызуда зур тырышлык күрсәткән төзүчеләргә бүләкләр дә әзерләгән иде. Ул түгәрәк уртасына беренче итеп Ерыкиренне чакырды:

– Туган, син бик зур батырлык күрсәттең. Күксу халкы исеменнән сиңа шушы медальне тапшырырга рөхсәт ит!

Каен тузыннан эшләнгән медаль зур ак чәчәккә охшаган иде, ә аның уртасына болай дип язылган:

Елтыркүз дә шундый ук бүләккә лаек булды. Аның артыннан түгәрәк уртасына тагын биш кондыз чыкты. Алар да Күксу кондызлары әзерләгән медальләргә ия булдылар. Ерыкирен исә бүләкләнүчеләр исеменнән күксулыларга рәхмәт белдерде.

Инженер буадашларының тырышлыгы хакында да онытмаган. Беренче булып бүләкне Кондызбай алды. Ап-ак каен тузына – медальгә түбәндәге сүзләр төшерелгән иде:

Кондызбайның йөзе кояш кебек балкыды. Кондызлар күрсәткән бу хөрмәткә ул бик рәхмәтле иде. Эштә өлгер тагын берничә яшь кондыз да аерым игътибарга лаек булды.

Тантананың рәсми өлеше озакка сузылмады. Аннан соң Күксу һәм Зәңгәр күл кондызлары, кулга-кул тотынышып, түгәрәктә бии башладылар, төрле уеннар уйнадылар. Бәйрәм әнә шулай бик озак дәвам итте. Бары кич җиткәч кенә, барысы да, бик канәгать булып, өйләренә таралыштылар.

Касыйм Нури улы Тәхаутдинов 1925 елның 10 сентябрендә Татарстанның Лениногорск районы Тукмак авылында дөньяга килә. Казан хәрби авиация техник училищесын (хәзер Казан югары артиллерия команда училищесы), Казан дәүләт университетының татар филологиясе һәм тарихы факультетын тәмамлый. «Социалистик Татарстан» (хәзер «Ватаным Татарстан») газетасында өлкән хәбәрче булып эшли.

Ул – «Куян күлмәге», «Кырмыска улы Кырмыскак маҗаралары», «Авыл парчалары» һ.б. китаплар авторы.

Касыйм Тәхау – Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан журналистларының Хөсәен Ямашев исемендәге премиясе лауреаты, Татарстан Язучылар берлегенең шәрәфле әгъзасы.

УДК 821.512.145-34-93
ББК 84(2Рос=Тат)-4
Т86

Рәссамы

*Рөстәм Хәбибуллин*

**Тәхау, К.Н.**

Кондызлар илендә : балалар өчен әкият / Касыйм Тәхау. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2010. – 46 б. : рәс. б-н.

ISBN 978-5-298-01915-6

Китапта авторның кече һәм урта яшьтәге мәктәп балалары өчен язылган әкияте бирелә. Әкият аша укучы серле кондызлар дөньясы белән таныша, маҗаралы вакыйгаларга очрый.

УДК 821.512.145-34-93

ББК 84(2Рос=Тат)-4

Литературно-художественное издание

Для детей младшего и среднего школьного возраста

**Тахау** Касым
(**Тахаутдинов** Касым Нуриевич)

**В СТРАНЕ БОБРОВ**

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

Кече һәм урта яшьтәге мәктәп балалары өчен

**Тәхау** Касыйм
(**Тәхаутдинов** Касыйм Нури улы)

**КОНДЫЗЛАР ИЛЕНДӘ**

Мөхәррире *Э.Т.Кәлимуллина.* Бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин.* Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Ф.Р.Гыйсмәтуллина.* Корректоры *Г.М.Хәбибуллина.* Оригинал-макеттан басарга кул куелды 28.12.2010. Форматы 60x90 1/8. Басма табагы 6,0. Тиражы 3000 д. Заказ О-708. Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19. **http://tatkniga.ru e-mail: tki@tatkniga.ru.** Оригинал-макет JahatTM программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. «Татмедиа» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы. 420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.

ISBN 978-5-298-01915-6

© Татарстан китап нәшрияты, 2010

© Тәхаутдинов К.Н., 2010